ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКАИ ТАТАРСТАН
пер. Школьный, д.7,
д. Тойгузино, Менделеевский район,
Республика Татарстан, 423646

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт,
Тойгужа авылы, Менделеевск районы,
Татарстан Республикасы, 423646

Тел. (факс): 8(85549) 3-40-13
e-mail: Toyg.Men@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28 июль 2026 ел № 9

“Тойгуҗа авыл җирлеге” муниципаль
берәмлеге территориясендә
стационар булмаган сәүдә объектларын
урнаштыру схемасынраслау турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Тойгуҗа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын кушымта нигезендә расларга.

2. Биш көн эчендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруның күрсәтелгән схемасын Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына тапшырырга.

3. Әлеге карарны җәмәгать урыннарындагы мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Тойгуҗа авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сафин

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Тойгуҗа авыл

жирлеге башкарма комитетының 2026
елның 28 июлендәге 9 нчы номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Тойгуҗа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № п/п | Стационар булмаган сәүдә объектларының урнашу урыны исеме | Сатыла торган товар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объектлары тибы (павильон, киоск, автомагазин, автолавка, тонар, лоток контейнер) | Сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының стационар булмаган сәүдә объектларыннан файдалануы | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тойгуҗа авылы, Үзәк ур. №3, 30, 53, 81 йортлар янәшәсендә Яшьләр ур., №5 йорт янында | Азык-төлек, сәнәгать товарлары | Автолавка | кулланыла | Дүшәмбе, чәршәмбе, җомга ел әйләнәсе |
| 2 | Рус Сарсазы авылы, Урман ур. №19 йорт янында | Азык-төлек, сәнәгать товарлары | Автолавка | кулланыла | Дүшәмбе, чәршәмбе, җомга ел әйләнәсе |